ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__440__ от «_01_»____08____2018 г.

2018-2020 елларга Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районында
Россия Федерациясендә 2025 елга кадәр
Экстремизмга каршы тору Стратегиясен
гамәлгә ашыру буенча чаралар Планын раслау турында

Россия Федерациясендә 2025 елга кадәр экстремизмга каршы тору Стратегиясе чаралар Планының 60 пунктын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 7 апрелендә кабул ителгән 665 нче санлы боерыгының 5 пунктын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1.2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында Россия Федерациясендә 2025 елга кадәр Экстремизмга каршы тору Стратегиясен гамәлгә ашыру буенча теркәлеп килүче чаралар Планын ( алга таба-План) кушымтага нигезләнеп расларга.

2. Планны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнар район бюджеты акчалары хисабына тиешле финанс елына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

3. Планны гамәлгә ашыруда катнашучы җаваплы башкаручыларга, оешмаларга һәм учреждениеләргә ярты елга бер тапкыр, 20 июньгә һәм 20 декабрьгә кадәр, үтәлеш турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырырга тәкъдим итәргә.

4.Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (Никитин В.И.) Планның үтәлеше өчен җаваплы затлардан алынган мәгълүматларны берләштереп, билгеләнгән вакыт эчендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына җибәрергә.

5. “Мамадыш –информ” “Татмедиа” АҖ филиалына гражданлык бердәмлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән бердәм комплекслы мәгълүмат кампаниясен тормышка ашыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов